# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге
Чалпы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

18 март 2024 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 4 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 10.11.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” 10.11.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә 2024 елның 18 мартында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:
“Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 10.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 10.11.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамы, Яңа урам, Гагарина урамы, Казан урамы, Ленин урамы, Садовая урамы буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Чалпы авылында урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);

3) Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( материаллар сатып алу, профнастиль белән тышлау, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);

4) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Чалпы торак пунктында үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү).».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 517 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 273.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен – 273, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:
чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 10.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 10.11.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамы, Яңа урам, Гагарина урамы, Казан урамы, Ленин урамы, Садовая урамы буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Чалпы авылында урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);

3) Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( материаллар сатып алу, профнастиль белән тышлау, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);

4) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Чалпы торак пунктында үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү).».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Чалпы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районының Чалпы җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы А.М.Мөхәмәтшин